**БЕЗ ҺӘРВАКЫТ БЕРГӘ!..**

**БҮГЕНГЕ НОМЕРДА:** **“Әниләр көне” (2 бит)**

**“Мисс һәм Мистер Декабрь” (3 бит)**



# ЯШЬЛӘР КАЛАСЫ


Тираж 20 экземпляр

30-нчы Ноябрь Чәршәмбе

**Балалар һәм яшүсмерләр гәжите** ★ **http://vkontakte.ru/club30613368**


## ЯҢАЛЫКЛАР

Сәламәтлек театрлары конкурсында катнашкан “Яшьләр каласы” киностудиясе командасы ярдәме белән төшерелгән һәм ясалган ролик район буенча 3 урын алды.

26нчы ноябрь көнне ОБЖ фәненнән уздырылган олимпиадада безнең 11нче класс укучысы Айдар Саниев район буенча 3 урын алды.

26нчы ноябрь көнне безнең мәктәптә Әниләр көненә багышланган бәйрәм уздырылды.

Бу айда безнең мәктәпкә интерактив такта һәм проектор кайтты.

## БУ БИК КЫЗЫК

Иртәнге йокыны җиңү өчен алма ашау кофедан яхшырак.

Кырмыскалар беркайчан йокламыйлар.

Самолётта очу вакытында чәчнең үсү тизлеге ике мәртәбәгә арта

Балалар яз көне тизрәк үсә.

Һәрберегез үз тавышына кайтаваз ишеткәне бардыр, ә менә үрдәк бакылдавы беркайчан да кайтаваз бирми. Әлеге факт фән тарафыннан расланмаган, ни өчен шулай икәнен берәү дә белми.

"Мона Лиза"ның бары тик иренен ясауга Леонардо да Винчи 12 ел вакытын багышлый. Менә "серле елмаю”ның сере нидә!

Яңгыр вакытында сызгыру тавышы ераккарак тарала.

Кеше этләрне безнең эрага кадәр 10 000 ел элек кулга ияләштергән.

*Интернет ресурсларыннан алынган.*

## КОТЛЫЙБЫЗ

2нче ноябрь көнне безнең Зәбирә апаның туган көне узып китте.

***Зәбирә апа!***

*Котлыйбыз Сезне туган көнегез белән! Сезгә ныклы сәламәтлек, озын гомер, эшләрегездә уңышлар, балаларыгызның сәламәт һәм бәхетле булуын телибез!*

*Сезнең укучыларыгыз.*

★★★★★★★★★★

2нче декабрь конне безнең Вәсилә апаның туган көне.

***Вәсилә апа!***

*Котлыйбыз Сезне туган көнегез белән! Сезгә ныклы сәламәтлек, озын гомер, эшләрегездә уңышлар, балаларыгызның сәламәт һәм бәхетле булуын телибез!*

*Сезнең укучыларыгыз.*

# ӘНИЛӘР КӨНЕ

26нчы ноябрь көнне безнең мәктәптә Әниләр көненә багышланган бәйрәм уздырылды. Бәйрәмгә әзерлекне барлык класслар бөтенесе бергә алып бардылар. Иң беренчедән, Әниләр өчен чакырулар ясалды. Икенчедән, Зәбирә апа һәм Нәзирә апа җитәкчелегендә 8 – 11нче класс укучылары әниләр турында матур иншалар язып, әниләренең фотографияләрен алып килделәр. Шулай ук, 1 – 7нче класс укучылары әниләргә багышлап, рәсем ясап алып килделәр. Болар барысы да бәйрәм алдыннан стэндка урнаштырылды. Класс җитәкчеләре ярдәмендә укучылар бик матур биюләр, җырлар, шигырьләр әзерләгәннәр иде. Мәсәлән, 1 – 3 класс укучылары башта җыр белән безне сөендерделәр. Бәләкәй булуга карамастан, балалар, җыр җырлаганда, шул көйгә биеп тә күрсәттеләр. Ә аннан соң 1 – 3 класс укучылары башкаруында Американың "Кантри" биюен карадык. Малайлар һәм кызлар үзләренең бик оста икәнен күрсәттеләр. 5нче сыйныф укучылары оригиналь биюләр ратканын без күптән беләбез инде. Бу бәйрәмгә егетләр чегән биюен әзерләделәр. Биюлере кебек, киемнәре дә, бизәнүләре дә бик оригиналь итеп сайланган. Шунда ук, егетләр килгән кунакларга кәрт ачып, алда нәрсә көтәсен әйтеп тә бирделәр. 6-нчы сыйныф укучылары әниләргә багышлап шигырьләр бүләк иттеләр. Шигырьләрне моңлы җыр белән тәмамладылар. Бу бәйрәмдә 6ларның вальс биюенә оста икәнен күрдек, чөнки җыр көенә егетләр кызларны биюгә чакырдылар. 7нче класс укучылары сәхнәдә җырлый башласа, без бөтенебез дә егет кеше ничек җырларга тиеш икәнен аңлыйбыз. Тавышлары көчле, моңлы! 8нче класстан Илүзә Мухаметшина бәйрәм алдыннан безгә бишек җыры бүләк итте һәм скетчта әни ролен башкарды. Илүзәнең тавышын ишеткәч, күңелләр ачылып китә! Скетчта, шулай ук, Ильяс Шәмсетдинов, Рамазан Латифуллин, Флорис Давлетшин катнаштылар. Рамазанның һәм Ильяснең бик шәп артистлар икәнен без барыбыз да беләбез, бер бәйрәм дә бу егетләрдән башка үтми! Ә менә Флорисның бабай ролен башкаруы – сәхнәгә беренче тапкыр аяк басуы булды. Каушап торса да, Флорис үзен бик әйбәт күрсәтте. Безнең бәйрәмгә,алдагы елда мәктәпне тәмамлаган укучыбыз, Динар Шәйхетдинов килде. Кунакларыбыз өчен Динар җырлады. Бөтенебездә дә Динарның җырларын сагынуыбыз сизелде. Бәйрәмгә үзебезнең "Чулпан" балалар бакчасыннан да кунаклар килде. Бәләкәчләр безгә буш килмәгәннәр, бәләкәй булуга карамастан, балалар матур шигырьләр сөйләп, җыр җырладылар, безне сөендерделәр! Бәйрәм бик әйбәт һәм күңелле үтте. Бәйрәмдә катнашкан укучыларга, аларга ярдәм иткән укытучыларга, класс җитәкчеләренә, бакчадан килгән балаларга, кунакларга бик зур рәхмәт белдерәбез! Киләсе бәйрәмнәр дә шулай күңелле һәм матур итеп үтсен иде!

*Рания Сахапова, "Бәйрәмнәр бүлеге" корреспонденты*

# МИСС һӘМ МИСТЕР ДЕКАБРЬ

Кемнән сорама, күбесе мәктәптә укыган елларын иң бәхетле һәм кызык чак дип әйтәләр. Мәктәпне сагыналар, мәктәпкә кунакка килеп таныш йөзләр, йөрәккә якын кешеләр эзлиләр. Укытучылары белән сөйләшеп туя алмыйлар, әле бер нәрсәне, әле икенче нәрсәне искә төшереп. Ни өчен шулай ул? Чөнки мәктәптә моңсуланып утырырга вакыт юк. Укытучыларыбыз безнең өчен һәрвакыт берәр кызык нәрсә оештырырга ашыгалар. Менә шул кызыкларның дәвамы булып безнең яңа “Мисс һәм Мистер Декабрь” конкурсы килер. Кадерле дусларыбыз, бу конкурста бөтен укучыларыбыз да катнаша. Һәр айның 5нче числосыннан 25нә бу конкурс кабатланачак. Һәм 25нче май көнне жюри “Мисс һәм Мистер – 2012” исеменә лаеклы укучыларыбыз арасыннан кыз һәм егет сайлыйлар. Ай саен җиңүчеләр диплом белән бүләкләнәләр, ә уку елы азагында җиңгән укучыларыбыз диплом һәм истәлекле бүләк алачаклар. Бу конкурста катнашучылар җиңер өчен түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1. Көн саен формадан йөрергә, егетләрнең чәчләре кыска итеп кистерелгән, кызларнын чәчләре матур итеп үрелгән, бантик куелган, куллар чиста, тырнаклар кыска итеп киселгән, чиста, буялмаган. Һәрвакыт алмашка аяк киеме бар.
2. Көндәлектә тәртип өчен һәр атна саен “үрнәк” яки “5” билгесе торырга тиеш. Вакытында мәктәпкә килергә, соңга калмаска. Сүгенү, сугышу, бер-беребезне ничек тә кимсетү, укытучыларга, олы кешеләргә каршы әйтү тыела.
3. Ай эчендә 12 – 15 “бишле” билгесе алу. Икеләләр тыела. Көндә дәрескә әзер булу. Китапларны, дәфтәрләрне чиста һәм тышлап тоту.

Бу конкурс өчен редакция җаваплы, шуңа күрә без үзебезнең корреспондентыбыз Айзәрә Солтанованы конкурс җитәкчесе итеп куябыз. Айзәрә үзе дә катнашырга мөмкин. Безнең корреспондент көн саен, укучыларыбызны карап чыга,тәртип, китаплар һәм дәфтәрләр тотышы турында класс җитәкчеләреннән, уку сораулары буенча укытучылардан белә. Барысын да язып бара. 24 се көнне жюри белән бу язуларны карап чыгалар һәм бу ай җиңүчеләрен билгелиләр.

Жюри составы:

1. Асия Вагиз кызы Хәсәншина, мәктәбебезнең директоры.
2. Зәбирә Фәрит кызы Хәсәнова, мәктәбебезнең завучы.
3. Нәзирә Шәгәдәт кызы Латифуллина, мәктәбебезнең педагог-организаторы.
4. Алсу Идиятова, мәктәбебезнең Дума депутаты.

Сораулар белән 10нчы сыйныф укучысы Айзәрә Солтановага килергә, яки группага (**http://vkontakte.ru/club30613368**) кереп, шунда сорауларыгызны калдырырга. Сезгә тиз арада җавап бирерләр.

Катнашучыларга уңышлар теләп калабыз!

*Айзәрә Солтанова, “Конкурслар бүлеге” корреспонденты*

# ЯҢА ЕЛ ХАТЛАРЫ

Урамда ап-ак кар яуган, бураннар чыккалый. Кыш җиткәнен кайберләребез сизми дә калганбыздыр. Ашыкмыйча, сиздермичә, Яңа ел бәйрәме дә якынлаша. Яңа ел – иң күңелле бәйрәмнәребезнең берсе. Үзебезнең мәктәбебездә дә озакламый яңа ел бәйрәменә әзерлек башланыр, бер – беребезне бәйрәм белән котларбыз. Котлаулар да төрле формада була: сүзләр белән, открыткалар бүләк итү. Бу елдан башлап редакция мәктәп тормышына тагын бер яңалык кертә. 20нче декабрь көненнән башлап, 27нче декабрьга кадәр мәктәптә “Яңа ел хатлары” исемендәге почта, яки бер-беребезне яңа ел белән котлаулар язышуы, оештырыла. Почта редакция кабинетында саклаabove. Кадерле дуслар, бер атна эчендә, сез котлау хатлары язачаксыз, 27нче декабрь көнне почтальоннар сезнең хатларыгызны адрес буенча тапшырыр. Шулай ук, әйтеп китәбез, адресатларга VIP – открыткалар җибәрергә мөмкинлек булачак. Алар түбәндәге үрнәктә булачак:

1. Открытка + чәчәк
2. Открытка + шигырь
3. Открытка + кәнфит

Бу VIP – открыткаларны җибәрер өчен сез почта эшләгән көннәрне редакциябезнең баш редакторның ярдәмчесе Энҗе Хакимовага эндәшергә тиеш буласыз. Барлык сорауларыгызны шулай ук Энҗе Хакимовага, яки группада (**http://vkontakte.ru/club30613368**) бирергә була.

*Энҗе Хакимова, баш редактор ярдәмчесе.*




Басылды: МБОУ “СОШ с.В. Стярле 20 экземпляр Телефон: 8 (85592) 42743

ЯШЬЛӘР КАЛАСЫ
**Баш редактор**
**Ильнур Марданшин**

**Редакция адресы:** 423314, ТР, Азнакай районы, Югары Стәрле авылы, Совет урамы, 38 Б, инглиз теле кабинеты, “Яшьләр каласы” гәҗите редакциясе.
**http://vkontakte.ru/club30613368**

Гәҗит аена бер тапкыр чыга, сату хакы – килешү буенча.

**Баш редактор ярдәмчесе:**Э.Хакимова
**Конкурслар бүлеге:** А. Солтанова
**Бәйрәмнәр бүлеге:** Р. Сахапова
**Беренче бит бүлеге:** Р. Латифуллин
**Фотограф:** Г. Хайбрахманова
**Художник:** И. Марданшин
**Комп.вёрстка:** Г.И.Хайруллина